Татарстан Республикасы
Чирмешән муниципаль районы
«Лашман авыл җирлеге»
муниципаль берәмлеге
гражданнары җыены

**КАРАРЫ**

Татарстан Республикасы
Чирмешән муниципаль районы Лашман авыл җирлеге
составына керүче Лашман торак пунктында

19 октябрь 2023 ел . № 2

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы Лашман авыл җирлегенең Лашман торак пунктында халык җыены **КАРАР ИТТЕ:**

1. 2024 елда Чирмешән муниципаль районы Лашман авыл җирлегенең Лашман торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәм яшәүче һәр балигъ булган кешедән 500 сум күләмендә гражданнарның үзара салымын кертергә көндезге уку формасы буенча белем алучы студентлардан, Россия Федерациясе Кораллы Көчләре сафларында хезмәт итүчеләрдән, Луганск халык республикасында һәм Донецк халык республикасында махсус операцияләрдә булган затлардан, Әфганстанда һәм Чечняда хәрби хәрәкәтләрдә катнашучылардан, 1 төркем инвалидлардан, балачактан инвалидлардан, 90 яшьтәге һәм аннан өлкәнрәк гражданнардан тыш.

2. Алынган чараларны түбәндәге эшләргә җибәрергә:

- Лашман, Әмир торак пунктларында урам утларын монтажлау, урнаштыру, ремонтлау, карап тоту һәм хезмәт күрсәтү, кулланылган электр энергиясе чыгымнарын түләү, югарыда күрсәтелгән эшләрне (хезмәтләрне) үтәү өчен кирәкле материаллар сатып алу;
- Лашман, Әмир торак пунктларында җирле әһәмияттәге урам юлларының чокырларын ремонтлау, ясалма тигезсезлек төзү, югарыда күрсәтелгән эшләрне (хезмәтләрне) үтәү өчен кирәкле материаллар сатып алу;
- җәйге һәм кышкы чорда җирле әһәмияттәге юлларны төзекләндерүгә, карап тотуга, хезмәт күрсәтүгә чыгымнар (юл кырыйларын чабуга, юлларны грейдерлауга, юлларны кыш көне кардан чистартуга) Лашман, Әмир торак пунктларында, ягулык-майлау материаллары һәм трактор өчен запас частьләр сатып алуга, тракторчыга исәпләнгән хезмәт хакына, югарыда күрсәтелгән эшләрне (хезмәтләрне) башкару өчен кирәкле материаллар сатып алу өчен чыгымнар;
- Лашман, Әмир авылларында халык күпләп ял итә алсын өчен шартлар тудыру һәм җәмгать киңлекләрен төзекләндерү;
- Лашман торак пунктында Бөек Ватан сугышы һәйкәле, тыл хезмәтчәннәренә һәйкәл территориясендә ремонт эшләре.
- Лашман торак пункты мәчетенең тротуарын ремонтлау, брусчатка белән каплау.

- Әмир торак пунктының балалар ишегалды уен мәйданчыгы төзелешен финанслау.

- Лашман торак пункты территориясендә разведка-эксплуатация скважинасын бораулауга финанслау.

3. Халык җыены нәтиҗәләрен мәгълүмат стендларында урнаштыру юлы белән игълан итәргә: Лашман авылы, Совет ур., 55, Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы Лашман авыл җирлегенең рәсми интернет-сайтында Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә бастырырга.

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары регистрына кертү өчен җибәрергә.

Гражданнар җыенында рәислек итүче
Лашман авыл җирлеге башлыгы Р.Г.Фәттахов